КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 декабрь

г.Казань

№ 1278

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт комплексы өлкәсендә юридик затларның күргәзмә һәм башка чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 27 июнь, 605 нче карары белән расланган Транспорт комплексы өлкәсендә юридик затларның күргәзмә һәм башка чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт комплексы өлкәсендә юридик затларның күргәзмә һәм башка чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 27 июнь, 605 нче карары белән расланган Транспорт комплексы өлкәсендә юридик затларның күргәзмә һәм башка чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле

финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;»;

16 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин